МӘҮЛИД
Пәйгамбәребезнең юлы
→ 8 БИТ

САБЫЙГА
Йосыф галәйһиссәлам
→ 9 БИТ

СӘЛАМӘТЛЕК
Үләннәрнең шифасы
→ 12 БИТ

ӘДӘБИ СӘХИФӘ
Сөннәтче бабай
→ 14 БИТ

**СЕНТЯБРЬ, 2022**
№ 09 (326)

Татарстан мөселманнары Дския нәзарәте басмасы

сафәр, 1444

# دين ومعيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

12+



Фото: dumrt.ru

**30 ел элек, 1992 елның 15 сентябрендә Татарстан Республикасында татар иҗтимагый тормышында иң мөһим институтларның берсе – ТР мөселманнарының Диния Нәзарәте барлыкка килде. Аның шушы еллар эчендәге эшчәнлеге, бүгенге торышы турында 4нче биттә тулырак таныша аласыз.**

ДӘВАМЫ → 4 НЧЕ БИТТӘ

ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ БУЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ!

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 09 (326) сентябрь, 2022 | сафәр, 1444

# Татар мәкамен торгызып буламы?

**Нәзарәттә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм җырчы, «Татар азаны» бәйгесен оештыручыларның берсе Марсель Вәгыйзов очрашып, азанны татар мәкаме белән әйтү традицияләрен торгызу һәм популярлаштыру турында фикер алыштылар.**

Азан әйтүнең аерым сәнгать икәнлегенә басым ясап, Камил хәзрәт иң элек төрекләрнең бу өлкәдәге тәҗрибәсе белән таныштырды һәм аларда азан әйтү буенча тулы бер фәнни мәктәп – бик зур мирас барлыгын искәртте. Мисал өчен, госманлыларда 600 төрле мәкам барлыгын, шуның бишесе азан әйтүдә актив кулланылуын хәбәр итте, азан төрле мелодикада әйтелә, имамнар тавыш уйната белә, һәр намазга азан үзенә күрә төрле рәвешләр белән әйтелә, дип искәртте. Мөфти татар мәкамен дә шулар үрнәгендә торгызып, билгеле бер кагыйдәләргә таянып, биш вакыт намазда азанның 5 төрле әйтелешен раслау, рәсмиләштерү һәм имамнар арасында тарату ниятләре белән таныштырды.

Марсель Вәгыйзов сүзләренчә, татар мәкаме 5 нотага – пентатоникага корылган. Ул татар мәкамен мөнәҗәтләргә нигезләнеп, нотага төшереп рәсмиләштерү фикерен әйтте.

Очрашуда шулай ук киләсе Мәүлид чарасында татар мәкаме белән дәрес итеп уку үрнәкләрен тәкъдим итү хакында да фикерләштеләр.



Фото: pressalmet.ru

# Әлмәт шәһәрендә яңа мәчет ачылды

**Әлмәт шәһәренең Агропоселок бистәсе «Нурлы» дип исемләнгән яңа мәчетле булды. Чараны Татарстан мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары Равил хәзрәт Зөфәрев ачып җибәрде. Ул, әлмәтлеләрне мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән сәламләп, Аллаһы Тәгалә йортлары – мәчетләрнең җәмгыятьтәге әһәмиятенә тукталды.**

– Бүгенге көндә республикабызда 48 мөхтәсибәттә 1500 мәчет эшләп килә. Әлмәт мөхтәсибәте халыкка ислам диненең җиткерү буенча зур эшләр башкара. Яңа ачылган «Нурлы» мәчете дә, әлмәтлеләргә озак еллар хезмәт итеп, гыйлем учагы булып калыр, – дип белдерде Равил хәзрәт.

Чарада мөселманнарны шулай ук Әлмәт шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе Айнур Исхаков, Әлмәт районы имам-мөхтәсибе Исмәгыйль хәзрәт Сөнгатуллин, Мөслим районы имам-мөхтәсибе Илгиз хәзрәт Сөнгатуллин, «Нурлы» мәчете имамы Мәгсүм хәзрәт Нуртдинов һ.б. котлады.

Мәгсүм хәзрәт Нуртдинов тантанада катнашучыларны мәчет төзелеше тарихы белән таныштырды. 2008 елда Габделәзәл хәзрәт Ибраһимов мәчет төзү өчен инициатив төркем булдыра. 2009 елда җир бүленеп бирелеп, 2010 елда мәчет төзелә башлый, төзелешкә Әлмәт халкы һәм меценатлар үз өлешен кертә. 2020 елда манарага ай куелып, мәхәллә халкы әзер бүлмәләргә җәмәгать намазына йөри башлый. Ниһаять, быел мәчет тулысынча төзелеп бетеп, ишекләрен ачты. Ачылыш тантанасы җәмәгать белән өйлә намазы укып, мәчетнең ашханәсендә тантаналы төшке аш белән дәвам итте.

270 кв.метрлы яңа ике катлы мәчет 100 кешегә исәпләнгән. Цоколь өлеше дә булган мәчеттә ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен 3 таһарәтханә, дини дәресләр өчен уку сыйныфлары, фарыз заллар, никах уку һәм исем кушу өчен бүлмәләр, имам бүлмәсе бар. Мәчеттә Рамазан аенда ифтарлар уза, газы, суы кергән, электр энергиясе белән тәэмин ителгән, канализация системасы ясалган.



Фото: dumrt.ru

## «Мөселманнар өчен банк карталары» проекты эшләнде

**Нәзарәтнең Голәмәләр шурасы «Ак Барс» банкы белән берлектә «Мөселманнар өчен банк карталары» проектын эшләде һәм раслады.**

Шәригать нормаларына туры килгән дебет картасы эчтәлеге буенча – банкның стандарт карталы продуктларына якын.

Ислам нормалары нигезендә, картаның шактый өстенлекләре бар: хисаптагы акчага процентлар исәпләнми; клиентларның акчалары аерым хисапларда саклана; әлеге хисаплардагы акчалар шәригать тарафыннан тыелган эшчәнлекне финанслауга файдаланылмый. Карталар казино һәм теләсә нинди уен һәм лотерея бизнесы хезмәтләре; исерткеч һәм тәмәке сатучы махсус кибетләрдә товар алу өчен каралмаган, шул ук вакытта әлеге чикләүләр продукция сатучы универсаль кибетләргә кагылмый. Бу карта белән барларда һәм төнге клубларда түләп булмый, ләкин чикләүләр рестораннар һәм кафеларга кагылмый.

**dumrt.ru** сайтыннан

# Яңа уку елы яңа бинада башланды



Фото: dumrt.ru

**1 нче сентябрьдә (сәфәр аеның 5 нче көнендә) Татарстанның мөселман уку йортларында Белем көне уңаеннан тантаналар узды. Мәдрәсә бусагасын беренче атлап керүче «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләрен Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин тәбрикләде һәм үз нәсыйхәтләрен бирде. Белем көне биредә мәдрәсәнең төзелгән яңа бинасында – актлар залында үтте.**

Уку йортының шәригать бүлегенә беренче курска 32 егет, 37 кыз, Коръән ятлау бүлегенә 12 егет, 7 кыз кабул ителде. Алар IX һәм XI сыйныфны тәмамлап, илебезнең төрле төбәкләреннән җыелды. Биш елдан шәкертләр мәдрәсәне тәмамлап, имам-хатыйб, ислам фәннәре һәм гарәп теле мөгаллиме, гарәп теленнән тәрҗемәче, Коръән-хафизлар булып, югары әзерлекле белгечләр булып чыгачак.

Белем көне тантанасын мәдрәсәнең II курс шәкерте, Коръән-хафиз Булат Шәрипов ачып җибәрде, аннары Татарстан мөфтие һәм мәдрәсәнең җитәкчесе Камил хәзрәт Сәмигуллин дога кылды һәм шәкертләр алдында үгет-нәсыйхәт сүзләре белән чыгыш ясады:

– Гыйлем турында хәдисләр бик күп. Бу дөньяда укылган барча китаплар бары бер китапны аңлар өчен укыла: ул – Коръәни-Кәрим. Бохари җыентыгында шундый бер хәдис бар: «Сезнең иң хәерлегез – Коръәнне өйрәнүче һәм аны башкаларга да өйрәтүче». Биредә укылган барлык фәннәр дә Коръәннең тәфсире булып торачак. Барлык гыйлемнәр Коръән белән башлана һәм Коръән белән тәмамлана. Иң төп максатыбыз – Коръәнне аңлап, укып, өйрәнеп, башкаларга аңлату. Сез биш ел дәвамында белем алырга дип көндезге бүлеккә килдегез, динебезгә, милләтебезгә файдалы булырсыз дип ышанабыз.

Шәкертләрне тормышында яңа этап башлануы белән тәбрикләү сүзләрен шулай ук мәдрәсә директорының беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин һәм Казан шәһәренең баш мөхтәсибе Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин җиткерде. Алар шәкертләргә мөрәҗәгать итеп, вакытның кадерен белергә, әдәп-әхлакны сакларга, җитәкчеләрнең, остазларның сүзен тыңларга чакырдылар. Аннары мәдрәсәнең директор урынбасары Зөлфәт хәзрәт Габдуллин күренекле галим Ризаэддин Фәхреддиннең «Шәкертлек әдәбе» китабыннан «Тәртип булса, аз мәшәкать белән күп файда алып була» дигән сүзләрне китереп, мәдрәсәнең эчке тәртип кагыйдәләре белән таныштырып үтте.

Соңыннан мөфти Камил хәзрәт шәкертләргә студент билетларын тапшырды һәм остазлар аларны беренче дәресләргә озатты.

Әйтергә кирәк, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре заманча, барлык уңайлыклар тудырылган шартларда, яңа уку классларында дәресләрне башлап җибәрде. Бинадар «ТР мөселманнарының Диния Нәзарәте резиденциясе» бердәм территориаль комплексын булдыру проекты кысаларында төзелде. Эшләр 2021 елның май аенда башланган иде һәм быел мәдрәсәнең 140-еллыгы уңаеннан Республика көне һәм яңа уку елы башлануга тәмамланды.

Мәдрәсә шәкертләре өчен тулай торак булдырылды. Ул 3 катлы, гомуми мәйданы 2 174,45 кв.м. тәшкил иткән бина итеп төзелде. Биредә, торак урыннарыннан тыш, мөстәкыйль уку класслары, медпункт, спортзал һәм башка техник бүлмәләр урын алды. 2020 елга кадәр шәкертләр мәдрәсәнең тарихи бинасында яшәде. 2021 елда реставрация эшләре башкарылып чыккач, анда хәзер 7 уку сыйныфы, инвалидлар өчен 2 уку сыйныфы, 2 лингофон кабинеты, 2 информатика кабинеты, уку залы урнаштырылды.

Тулай торак җир өстендәге кичү аша мәдрәсәнең яңа административ корпусы белән тоташкан. Әлеге бинаның гомуми мәйданы – 2 798,67 кв.м. Корпус үз эченә 3 уку сыйныфын, 118 кешелек конференц-залны, ашханә, мәдрәсә җитәкчелеге һәм хезмәткәрләре кабинетларын һәм башка ярдәмче мәйданнарны алган.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе – татар халкының йөзек кашы, аңа 1882 нче елда нигез салынган. Биредә төрле елларда Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Кәрим Тинчурин, Солтан Габәши, Мәҗит Гафури кебек татар зыялылары белем алган. Хәзерге вакытта да мәдрәсә җитәкчелеге киң карашлы, югары белемле, яхшы әзерлекле белгечләр әзерләү өчен зур көч куя. Дини фәннәрдән тыш, мәдрәсәнең уку программасына информатика, инглиз теле, татар теле дәресләре кертелгән. Информатика дәресләре махсус җиһазландырылган компьютер классында үтә. Мәдрәсәнең бай китапханә фонды шәкертләргә курс һәм диплом эшләрен җиңел һәм тиз язу мөмкинлеге бирә. Уку йортында даими рәвештә Коръәнне яттан белү бәйгеләре, кул эшләре күргәзмәләре, спорт чаралары, шул исәптән башка уку йортлары белән футбол, теннис, волейбол, җиңел атлетика буенча ярышлар, дини темаларга конференцияләр, мавыктыргыч экскурсияләр үткәрелә.

Белем көне уңаеннан тантаналар Татарстанның барлык дини уку йортлары шәкертләре өчен дә үткәрелде. «Мөхәммәдия»дән кала, Казанда беренче курска көндезге бүлеккә укырга шәкертләр Казан ислам университетына – 48, Рәсәй ислам институтына 51 егет һәм кыз килде.

**dumrt.ru** сайтыннан

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 09 (326) сентябрь, 2022 | сафәр, 1444

# 1992 елда ТР Диния Нәзарәте барлыкка килгән

## Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның Татарстан Диния Нәзарәте оешуга 30 ел уңаеннан мөрәҗәгате

**Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахииим.**

**Хөрмәтле хәзрәтләр, мөхтәсибләр, имамнар, абыстайлар, остазлар! Газиз дин кардәшләр! Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!**

Моннан 30 ел элек, 1992 елның 15 сентябрендә Татарстан Республикасында татар иҗтимагый тормышында иң мөһим институтларның берсе – ТР мөселманнарының Диния Нәзарәте барлыкка килде. Бу истәлекле дата уңаеннан мөфтиятнең чишмә башында торган, аның башлангычларын тормышка ашырырга ярдәм иткән һәм республикада Ислам дине үсеше өчен тырышкан һәркемгә – дини эшчәнлек ветераннарына, бүген дә Аллаһы юлында хезмәт куючы имамнарга һәм белгечләргә, Татарстан җитәкчелегенә, дусларга, фикердәшләргә һәм көрәштәшләргә рәхмәт белдерәм!

90-нчы елларда Рәсәй җәмгатьчелегендә башланып киткән үзгәрешләр илдә һәм республикада дини кыйммәтләрне кайтару өчен күп мөмкинлекләр тудыра. Татарстанда бер-бер артлы мәчетләр ачыла башлый, мәдрәсәләр барлыкка килә, китаплар чыга... Мөселман инфраструктурасы үсә барган саен Татарстанда дини мәсьәләләрне оешкан төстә хәл итү өчен аерым дини идарә булдыру ихтыяҗы да туа. Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния Нәзарәте тарихы әнә шулай башлана.

Рәсәйнең беренче мөселман Диния Нәзарәте Екатерина II указы буенча дин әһелләрен контрольдә тоту максатында булдырылганга күрә, илебездә мөфтиятләргә карата тискәре фикерләр хөкем сөрә. Әмма Татарстан мөфтияте дин кардәшләребезнең үз ихтыяры белән барлыкка килә. Аны булдыру – иманга һәм рухи башлангычларга кайткан, атеистик йокыдан айныган, дини ихтыярга һәм хак әхлакый кыйммәтләргә омтылган татар халкының үз теләге. ТР МДНнә нигез салучыларның ниятләре әнә шундый булган. Кызганычка, аларның кайберәүләре безнең арадан китеп барды, без – аларның рухына догада. Кем белә, бәлки, мөфтияткә Үзенең бәрәкәтләрен Аллаһы Тәгалә аларның ихлас ниятләрен күреп биргәндер. Татарстан мөселманнары шулай ук Нәзарәт барлыкка килүнең тере шаһитларына – ветеран-имамнарга, динебез хакына эшчәнлеген дәвам итүче хәзрәтләргә карата да тирән, чиксез хөрмәт белән карый. Раббыбыз аларның игелекләрен кабул итсен һәм күп әҗер-саваплар белән бүләкләсен!

Билгеле, Татарстан мөфтиятенең бүгенге күпсанлы уңышлары аның 1990 еллардагы башлангыч, фундаменталь казанышларына нигезләнә. Мисал өчен, ТР МДН III Съездының, соңыннан тарихка берләшү съезды исеме белән кереп калган корылтайның әһәмиятен бәяләп бетереп булмый, чөнки ул 1994 елдан бирле республикада берьюлы эшләп килгән ике дини оешманы – ТР МДН һәм Татарстанның төбәк МДН берләштерә. Моннан тыш, бу чор ислам мәгарифе системасы барлыкка килү һәм мөселман инфраструктурасы формалаша башлавы белән дә истәлекле: бүгенге көндә эшләп килә торган барлык мәдрәсәләр һәм ислам югары уку йортлары, шулай ук хәзерге мәчетләрнең күпчелеге Нәзарәт гомеренең беренче яртысында үз ишекләрен ачып җибәрә. Бүген Татарстан өммәте үзенең үсешен шушы нигездә дәвам итә.

Соңгы елларда ТР МДН – алдынгы мөфтиятләрнең берсе, ә республика – Рәсәйнең ислам үзәге дигән абруй казанды. Аллаһының ярдәме белән, Татарстан өммәтенең рухи һәм интеллектуаль көче, дини-фәнни белгечләре, шулай ук ил һәм республика җитәкчелегенең, дин кардәшләр һәм дусларның терәге бәрабәренә бик күп төрле эш юнәлешләрендә ТР МДН алгы сафларда тора.

Иң зур казаныш – Коръән бастыруның татар традицияләрен кайтару, Рәсәйдә Коръәннең мәгънәләрен аңлау өчен заманча фундаменталь базаны булдыру һәм ислам дөньясында Коръәнне әзерләп чыгару буенча эксперт буларак танылу. 1803 елда «Казан басмасын» бастыру ислам дөньясында зур вакыйга булган кебек, 2022 елда аны бүгенге халыкара стандартларга туры китереп яңарту кабат бөтен мөселман өммәтенең игътибарын татарларга җәлеп итә.

Татарстанда ислам мәгарифенең күпбаскычлы система буларак формалашуы да зур әһәмияткә ия. Бүген бу система үз эченә 700 мәчет каршындагы курсларны, 8 мәдрәсә, 2 югары уку йортын һәм Болгар ислам академиясен ала: республикада дини гыйлемле нигезләрдән алып, академик дәрәҗәгә кадәр үзләштереп була.

Нәзарәтнең күзгә күренерлек уңышлары – нәшрият өлкәсендә дә. «Хозур» Нәшрият йорты 2013 елда барлыкка килә һәм шушы вакыт эчендә Рәсәйдә иң эре мөселман медиахолдингларның берсенә әверелә. Нәшриятта 300-дән артык төрле исемдәге китаплар, шул исәптән бестселлерлар һәм фундаменталь хезмәтләр дә чыга, 6 мөселман массакүләм мәгълүмат чарасы барлыкка килә. Аларның берсе – «Хозур ТВ» мөселман телеканалы.

Вакф институтын үстерү дә Нәзарәтнең өстенлекле эш юнәлеше булып тора. 2011 елда «ТР Вакфы» фонды барлыкка килде һәм шул вакыттан бирле бүгенгә кадәр Татарстан өммәте милегенә 1592 объект рәсмиләштерелде, аларның 84е мәдәни мираска карый.

Шулай ук «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең инфраструктурасын киңәй-



Фото: dumrt.ru

*Иң зур казаныш – Коръән бастыруның татар традицияләрен кайтару, Рәсәйдә Коръәннең мәгънәләрен аңлау өчен заманча фундаменталь базаны булдыру һәм ислам дөньясында Коръәнне әзерләп чыгару буенча эксперт буларак танылу.*



Фото: dumrt.ru

тү дә зур шатлык булды: аның тарихында хәзергесе кебек материаль-техник база моңарчы булганы юк иде.

Мөфтият татар җәмәгатьчелегеннән мәчетләрдә татар телле мохитны саклау өлкәсендәге тырышлыклары өчен дә күп рәхмәтләр ишетә. Мәчет каршындагы татар теле курслары, татарча онлайн-мәдрәсә, татар телен өйрәнү өчен онлайн-платформа, татарча вәгазьләр – шушы һәм башка күпсанлы татар телле проектлар милли-дини мәдәниятнең үзенчәлекләрен саклап калырга мөмкинлек бирә.

«Нигезләмә» – республикада сөнни ислам кыйммәтләрен саклау буенча нигезле документ. «Татарстан Республикасы мөселманнары Диния Нәзарәте имам-хатыйблары тарафыннан гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында нигезләмә»не эшләүдә барлык имам-мөхтәсибләр, Нәзарәтнең Галәмәләр шурасы, Казыйлар шурасы һәм Шәригать белгечләре бергә катнашты.

Хәйриячелек өлкәсендә дә Диния Нәзарәте җитди эшчәнлек алып бара. 2016 елдан бирле ул системалы рәвештә тормышка ашырыла башлады. Нәтиҗәдә, соңгы 6 ел эчендә мөфтиятнең «Зәкят» Хәйрия фонды 500 авыру кешенең дәвалану курсларына акча күчерде, 24 мең мохтаҗга азык-төлеклә тә ярдәм күрсәтелде.

Казыятләр системасы, бердәм хәләл стандартларын эшләү, «Даруль ифта» фәтвалар call-үзәге, Рәсәй дини-иләһият мирасының Darul-Kutub.com электрон китапханәсе, онлайн-мәдрәсә, төрмәләрдә тәрбияви эш – Нәзарәтнең шушы һәм башка проектлары илебездә уникаль булып тора һәм Рәсәй мөселманнарын дөньякүләм өммәтнең абруйлы бер өлеше итеп күрсәтә. Бай рухи мираска, күпгасырлык мәдәнияткә, хәзерге заман дини-иләһият казанышларына ия булган өлеше итеп...

Газиз дин кардәшләрем! Тарих өчен 30 ел – күп түгел. Бигрәк тә бабаларыбызның Ислам динен рәсми рәвештә 11 гасыр элек кабул иткәннәрен игътибарга алсак. Әмма татарлар үзенең 1100-еллык рухи мирасын җуя язганын истә тотсак, 30 ел элек Татарстан мөфтиятен булдыру, һичшиксез, милләтебездә ислам тарихының яңа битен ачып җибәрде. Халык хәтере һәм иман, гыйлемгә һәм тарихи хаклыкка нәселдән-нәселгә күчеп килә торган омтылыш, туган нигезгә, кавемгә, гореф-гадәтләргә тугрылык – болар Аллаһы Тәгалә тарафыннан милләтебезнең канына сеңдерелгән. Вакытларга, гасырларга, тарихка бәйләнмәгән мәңгелек кыйммәтләр буларак, бу сыйфатлар – халкыбызның соңгы 30 ел эчендә ирешелгән рухи үсеш сәбәпләренең берсе. Шушы еллар эчендә Татарстандагы уңай үзгәрешләр – бәхәссез: республикада азан тавышы өзелми, мәчет-мәдрәсәләр төзелә, көчле экспертлар әзерләнә, хәләл яшәү рәвеше алга сөрелә, дини-иләһият фәне алга атлый, 2014 елдан бирле татар дөньясының үзәгендә – «Кол Шәриф» мәчетендә Коръән хәтем кылына башлап әлегә кадәр бер генә мизгелгә туктатылмый... Шушы үсешнең һәр баскычында имамнар, абыстайлар, белгечләрнең хезмәте тора. Раббыбыз дин юлында тырышлыкларны кабул итсен һәм бервакытта да республикабызда Аллаһы Китабының сүзе тынмасын!

**dumrt.ru** сайтыннан

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 09 (326) сентябрь, 2022 | сафәр, 1444

## Ринат Нәбиев:
# «Ислам дине кыйммәтләрен күрсәтә алу мөһим»




Фото: авторның шәхси архивыннан

**Ринат Әхмәтгали улы Нәбиев – Казан (Идел буе) федераль университетының тарих һәм сәясәт кафедрасы мөдире, тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, 200дән артык гыйльми хезмәт авторы. 1997-2006 елларда – Татарстан хөкүмәте каршындагы дин эшләре советы рәисе.**

**– Ринат Әхмәтгалевич, быел ТР Диния Нәзарәте зур датаны – үзенең 30 еллыгын билгеләп үтә. Нәзарәтнең ул елларда беренче адымнарын ясый башлавы, җәмәгатьчелек тарафыннан кабул ителүе хакында сөйләп узсагыз иде.**

– 90 нчы еллар милли, дини яңарыш чоры иде. Шушы чорның бер үзенчәлеге – ул дини яңарыш һәм милли яңарышның бергә «кулга-кул» тотынышып баруын, Габдулла хәзрәт Галиулланың эшчәнлеген әйтер идем. Әлбәттә, икенче яктан караганда, дин белән милләт аерым булырга тиеш. Ислам дине бу очракта милләтне аермый да, Исламга килгән барлык кешеләр дә мөселман өммәтенә керә. Коръәндә дә: **«Кавем-кавем итеп яраттым»**, – дип әйтелгән («Әл-Хуҗҗурат / Бүлмәләр», 49:13). Шуңа күрә дә бу үзенчәлек нык ярылып ятмаса да, Ислам дине дөньякүләм дин буларак, барлык ышанучыларны милләткә, ниндидер социаль төркемнәргә бүлми. Әмма шулай килеп чыкты: шушы чорда милли хәрәкәт һәм дини яңарыш хәрәкәте бергә үрелеп барды. Әлбәттә, бу күренешнең уңай яклары да, шул ук вакытта тискәре яклары да бар иде. Бу акрынлап 90 нчы еллар уртасында сизелә башлады.

1992 елны ТР Диния Нәзарәте барлыкка килә. Ул татар халкының үзбилгеләнү чоры, ничек тә булса яңарышны тизләтү, мәсәлән, мәдәниятне, телне, динне үстерү теләге туган вакыт иде. 90 нчы елларның башы боларның барысы да укмашкан рәвештә баруы белән үзенчәлекле иде.

90 еллар башы тәртипкә салынмаган чор иде. Аның шулай булуында, әлбәттә, кабул ителгән законнар да роль уйный, аларның да тәэсире була, чөнки 90 елда кабул ителгән «Вөҗдан ирегә буенча» РФ законы һәм Советлар Союзы законнарында ачык рәвештә, бернинди каршылыксыз дин ирегә чиксез дип табыла.

1996 елны яңа закон эшли башлыйлар. Ул РФ законы була һәм 1997 елның 1 нче октябрендә кабул ителә. Анда билгеле бер кысалар барлыкка килә башлый. 1997 елның июнь аенда ул вакыттагы Президентыбыз Минтимер Шәрипович мине шул эшкә – ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Дин эшләре советы рәисе итеп чакырды. Ул вакытта мин фәннәр докторы, профессор идем. Мәскәүдә дәүләтдин мөнәсәбәтләре буенча докторлык эше яклаган идем. Мәскәүдә Президент Администрациясендә дә сәяси репрессия корбаннарын яклау бүлегендә эшләп алдым. Анда калу да тәкъдим ителгән иде, мин Татарстанга кайттым.

Бу эшкә тотынгач без аңа бар игътибарыбызны биреп эшли башладык. Безнең үзебезнең фәнни төркем бар иде. Ул «Җәмгыять, мәдәният һәм дин» дигән оешма иде. Ул «Общественный научно-экспертный институт» («Иҗтимагый фәнни-эксперт институты») булып формалашты.

Безнең үз басмаларыбыз да бар иде. Һәр елны серия рәвешендә 27 китап бастырдык, Ислам буенча энциклопедияләр чыгардык. Шулай ук конференцияләр, «түгәрәк өстәлләр» үткәрә идек. Галимнәрдән торган әлеге төркем шундый көчле итеп эшләп китте. Ул безнең «Дин эшләре Советы»ның «кайнап торган үзәге» иде. Нәрсә башка суга, шуны эшләп түгел, ә нәкъ менә тикшереп, уйлап эш итә идек. Менә шунда без уйлаштык һәм Минтимер Шәриповичка берләштерү съезды үткәрү тәкъдиме белән чыктык.

1998 елның 14 нче февралендә үткәрелгән съезд дини яңарышның, Ислам үсешенең барышын, киләчәген билгеләгән, рәткә салган бер вакыйга булды.

Мин 1992 елдан 1998 елга кадәр булган вакытны оешу чоры дип карыйм. Халык кемгә мөрәҗәгать итәргә дә белми, ураза һәм садакага кагылышлы мәсьәләләрдә дә буталчык бар иде. Боларны аңлау, мөселманнарның борчылып йөрүләрен күрү, әлеге съездны үткәрүнең әһәмиятен күтәреп чыгарды. Шуңа да 1998 елның 14 нче февралендә үткәрелгән әлеге съездны беренче съезд дип атау – ул дөрес. Әлбәттә, аның беренче чыганаклары, башлангыч чоры – 1992 ел. Әмма нәкъ менә закон кабул ителү, Рәсәй Ислам Университеты ачылу 1998-1999 елларда була. Без оешып, Диния Нәзарәте булып яңа гасырга аяк атладык. Сүз дә юк, 1992 елдан 1998 елга кадәр булган чорны бернечек тә сызып ташлый алмыйбыз. Бу бик җаваплы булган оешу, уяту чоры булып кала.

Закон кабул иткәндә, киләчәктә бүленеш булмасын өчен, законга, ТРда бер мөфтият төзелә, дигән матдә керттек. Бу съездның төп карары – берләшеп, бер мөфти сайлау иде. Монда алты кандидат бар иде, шулар арасыннан иң күп тавыш бирү белән, Госман хәзрәт Исхакый беренче булып чыкты.

Шул рәвешле съезд үтте, мөфти сайланды. Мөфти беренче урынбасарны һәм Баш казыйны тәкъдим итәргә тиеш иде. Моны мин Уставка кертүне тәкъдим иттем, мөселманнар кабул итте. Бу мөфтиятне бер йодрыкка җыйды да куйды.

**– Ул елларда дөньяви дәүләттә дини структура барлыкка килү диндә булмаган кешеләр тарафыннан ничек кабул ителде дип уйлыйсыз?**

– 90 елларда бер бушлык барлыкка килә. Коммунистик идеология китә. Төрле хәрәкәтләрнең бәреп керүе дә шуның белән бәйле. Ислам дине буенча гына түгел, башка диннәр буенча да төрле юнәлешләргә кереп китүләр күзәтелә. Бу тирәнтен рәвештә дингә бирелгән кешеләрнең дә әлегә аз булган вакыты. Әйе, мәчетләр төзелә, әмма анда йөргән кешеләр юк дәрәҗәсендә. Бу чорда халык әле динне кабул итәргә әзер түгел иде. Димәк, матди рәвештә инде төзелеш барса да, рухи, дини байлык әле аз булган вакыт.

Сүз дә юк, кешеләр арасында динне кирәксез дип санаучылар да бар иде, әмма күп кешенең үзенең тарихына, мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә уңай караш саклана һәм шуңа да дингә милләтнең бер үзенчәлеге, традициясе итеп карау бар иде.

Минем әни бик тә дини кеше иде, Коръәнне яттан белә иде. 42 яшендә глаукома чиреннән сукыраеп, ул вакытларда бу чирне дәвалап булмады. Әни шуннан соң күрше, Коръәнне яттан белүче Акъәбиебездән Изге Китапны өйрәнде. Әнинең хәтере яхшы иде, ул сукырайган көе Коръәнне ятлап чыга алды. Әни миңа: «Улым, инде синең машинаң да, фатирың да, яхшы эшең дә бар. Авылыбызда мәчет төзесәң иде», – дип әйткән иде. Аллаһыга шөкер, әнинең сүзен үти алдым. Туган ягым Башкортстанның Чакмагыш районы Имәнлекүл авылында мәчет төзү эшләрен башладык. Шул вакытта кайберәүләр тарафыннан «Нигә бу эшләрне башлап йөрисең? Кемгә кирәк ул?» ише сүзләрне дә ишетергә туры килде. «Ярый инде, бер архитектур корылма булсын», – дип әйтүчеләр дә булды. Ә мин бу сүзләргә болай дип әйтә идем: «Әгәр хәмергә бирелгән бер генә кеше булса да, кибеткә барышлый, әлеге мәчеткә кереп, шуннан соң хәмерен ташласа, димәк, мәчет үз вазифасын үтәгән була».

**– Ринат Әхмәтгалиевич, мәчеткә нинди исем бирелде?**

– Мәчеткә «Гүләмзәм» дип, әниебез исемен бирдек. Әни 90 яшькә кадәр яшәде. Мәчетне 5-6 ел төзедек. 2011 елны әнинең хәле китә башлагач: «Әни, көт менә быел мәчетне төзү эшләрен тәмамлыйбыз», – дидем. Әни 1 апрель көнне вафат булды. Шул ук елның 26 августында мәчет үз ишекләрен ачып җибәрде.

**– Бу вакыттаниләр кичергән идегез?**

– Мин динне кеченәдән күреп үстем, ул миңа якын иде. Күңелдә дингә карата әни тарафыннан салынган хөрмәт бар иде. Әлбәттә, мәчет ачылганда миндә әнинең теләген үти алу куанычы зур иде. Бу мәчет элек хезмәт итеп, хәзер юкка чыккан мәчет урынында төзелде. Ачылышта халык күп иде. Мәчет Ураза бәйрәме алдыннан ачылды.

**– Бүгенге Диния Нәзарәтенә кайтык әле. Хәзерге көндә Нәзарәтнең күпкырлы эшчәнлек алып баруын күрәбез: төрле проектлар, хәйрия эшләре моның мисалы. Нәзарәт динне таратуда булдыра алганча тырышлык куя. Сезнеңчә, бу эшләрне алга таба да уңышлы башкару өчен, ниләр эшләнергә тиеш?**

– Бу юлда һәм социаль, һәм рухи-әхлакый, һәм белемгә омтылыш ягыннан кыйммәтләрне күрсәтә белергә кирәк. Исламның күркәм йөзен, безнең җирлектә, безнең халык арасында ролен күрсәтү мөһим. Шул очракта Ислам дине үзенең урынын тагы да ныгытачак. Үзәк линия, үзәк юл булырга тиеш бу.

Шундый күренеш бар: әгәр адәм баласы үзенең тамырларын, мәдәни традиция тамырларын киссә, ул радикальләшә, динне кабул иткәндә дә радикаль рәвештә кабул итә. Безнең Хәнәфи мәзһәбе сыгылмалы булуы, гореф-гадәтләрне дә искә алуы белән күркәм. Анда башка диннәргә тискәре караш күрмибез.

Күп еллар элек җәдитчеләр яңа сулыш кертә: адәм баласы бу тормышта актив булырга, үзенә башка казанышларны да сыйдырырга, заманa белән бергә барырга тиеш. Телен дә, традицияләрен дә белмәгән кеше дингә килә дә, радикальләшә. Шуңа да тирәнтен рәвештә гореф-гадәтләрне дә, тарихны да белергә, аны халыкка да җиткерергә кирәк.

**– Быел зур вакыйга – Болгар бабаларыбызның Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы билгеләп үтү халкыбызга чал тарихыбызны күрсәтүдә үз өлешен кертте дип саныйсызмы?**

– Моңа кадәр дә дәүләт дәрәҗәсендә үткәрелгән мондый чаралар бар иде. Чыннан да, аларның әһәмияте бик зур, халык өчен бу мөһим. Әгәр дәүләт мондый чараларны хуплап кабул итә икән, ул динара мөнәсәбәтләрне яхшырта, халыкта тынычлык булдыра, үзенең тарихына, диненә хөрмәт хисләре уянуга сәбәпче була.

Әңгәмәне **Айсылу Юлдашева** әзерләде

# ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ ЮЛЫННАН ТАЙПЫЛМЫЙК

**Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хакында Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:**

*«[Расүлем!] Без сине [җеннәр, фәрештәләр, кяфер һәм мөселман барча кешеләрне кертеп] бөтен галәмнәр өчен бер рәхмәт итеп җибәрдек»;*

*«Әл-Әнбия / Пәйгамбәрләр», 21:107*

Икенче бер аятьтә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

*«Сезнең өчен [бигрәк тә] Аллаһыга һәм Соңгы көнгә өмет баглаган һәм [курку, теләү, муллык һәм тарлык кебек бөтен хәлләрендә] Аллаһыны күп итеп искә алган кешеләр өчен Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмдә күркәм үрнәк бар».*

*«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:21*

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең тормыш юлы үрнәгендә башка диндә, икенче бер милләттән, башка төрле уй-фикердә булган кешеләргә карата нинди мөнәсәбәт булырга; нинди гамәлләр кылырга; алар белән сату-алу һәм башка мөнәсәбәтләрне ничек булдырырга; аларга карата нинди караш булырга тиешлеген безгә ачыктан-ачык күрсәтә. Ул хәтта үзенең ишек төбенә чүп атып киткән кешеләргә дә мәрхәмәтлелек белән карый торган булган. Аларга беркайчан да орынып, начар сүзләр әйтеп, начар гамәлләр кылмаган. Беркайчан да үзенә дорфа дәшкән кешеләргә дорфа итеп җавап кайтармаган. Аның динендә булмаган кешеләргә ул нәфрәт белән карамаган. Әгәр дә берәр кеше аның кебек фикерләмәсә, ул кешегә беркайчан да кычкырып, аны мыскыл итеп түбәнсетмәгән.

Әгәр дә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлын карасак, аны күпме генә рәнҗетсәләр, күпме генә кыерсытсалар да, ул бер кешегә барып та: «Син минем динемне мыскыл иттең», – дип сукмаган, рәнҗетмәгән, кыерсытмаган икәнен белербез. Ул беркайчан да башкаларга: «Сезнең динегез дөрес түгел. Сез мәсхәрәле кешеләр», – дип, аларга ярамаган сүзләр әйтеп каты бәрелмәгән. Киресенчә, аларга ягымлы караш белән, яхшы сүз әйтеп, күркәм мөгамәлә кылып яшәргә тырышкан.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: «Мөселман шул кешедер – кешеләр аннан беркайчан да курыкмаслар. Үзләренең малларын, җаннарын, тәннәрен, милекләрен иминлектә, дип хис итәрләр». Ягъни мөселман булган кеше беркайчан да гайбәткә, начар сүзләргә, начар гамәлләргә, мыскыллауларга, җәберләүләргә кучмәс. Киресенчә, ул бик мөлаем итеп аралашырга тырышыр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм намаз укыган вакытта аның өстенә дөя эчәкләрен һәм башка төрле нәҗесләрне ташласалар да, ул беркайчан да алар белән дорфа сөйләшмәгән. Киресенчә, мәрхәмәтле булырга тырышкан. Үзенең оныклары белән дә һәрвакыт көләч йөзле булып, шатланып алар белән уйнаган. Әгәр дә начарлыкны күрсә, матур итеп, хикмәт белән әйтә белгән.

Ислам дине тынычлык, матурлык һәм күркәм дин буларак таралды. Коръәни Кәримнең беренче булып иңгән аяте дә «Укы!» дигән сүз белән башлана, ягъни Раббыбыз безне гыйлем алырга чакыра. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә гыйлем туплап, шушы юлда үзеңнең малыңны кызганмыйча укырга, тырышырга, хезмәт куярга кирәк икәнлеген һәрвакытта да ассызыклаган.

Бервакыт бер көрәштән кайткач, сәхабәләре бик нык сөенгәндә, Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Без кечкенә көрәшне җиңдек, әмма алдыбызда иң зур яу бар». Сәхабәләре бу сүзләргә гаҗәпләнеп, Аллаһының Расүленнән: «Нинди яу соң ул? Моннан да көчлерәк яу була аламыни?» – дип сораганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип җавап биргән: «Әйе, әле алдыбызда иң зур яу бар. Ул да булса – нәфесебез белән көрәшү». Нәфесебезгә каршы тору, нәфесебез теләгән начарлыкларны булдырмау мөһим, ягъни һәр мөселманның каршысында иң зур көрәш – ул үз-үзе белән, үзенең нәфесе белән. Төннең уртасында намазга уяну, йокыңны җиңү – зур бер көрәш, нәфесеңне җиңү. Рамазан аенда ризыктан, эчемлекләрдән аерылып тору – шулай ук зур бер көрәш, нәфесеңне җиңү. Вакытыңны дөрес итеп куллану, гыйлем алырга тырышу да нәфесеңне җиңү. Ачуыңны чыгарган кешегә беренче булып елмаеп, янына килеп исәнләшү – зур батырлык. Боларның барысы да безгә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм тарафыннан өйрәтеп калдырылган гамәлләр.

Пәйгамбәребезнең өммәтенә, ә бигрәк тә сәхабәләргә мөрәҗәгать итеп, Раббыбыз әлеге сүзләрне әйтә:

*«Кешеләр [мәнфәгатьләрен кайгыртыр] өчен [мәйданга] чыгарылган өммәтләрнең иң яхшысы сез булдыгыз [Ий Мөхәммәд өммәте! Аллаһының мәңгелек гыйлемендә дә, Ләүхүл-Мәхфүздә дә бу саклана]. Яхшы гамәлләрне әмер итәсез, начар гамәлләрдән тыясыз һәм Аллаһыга ышанасыз».*

*«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:110*

Хакыйкый мөселман булган кеше һәрвакытта күңелендә изгелек йөртү сәбәпле, бөтен кешегә дә бәхет теләр, чөнки ул зур бәхетнең иманлы булып, кешеләргә изгелек кылып яшәү икәнен аңлый һәм башкаларга да шуны тели. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Үзегезгә теләгәнне башкаларга да теләмичә сезнең иманнарыгыз камиллеккә ирешмәс», – дип әйткән. Үзебезгә теләгән бәхетне калганнарга да теләсәк, алар белән яхшы мөнәсәбәттә булсак, һичшиксез, Аллаһы Тәгалә безнең шушы матур үрнәгебез, әхлагыбыз сәбәпле калган кешеләрне дә ислам диненә китерер. Без кешеләргә динебезнең никадәр матур, гүзәл, күркәм икәнен күрсәткән саен, алар безнең динебезгә тартылырлар.

**Алмаз хәзрәт Галимҗанов,**
Саба районы имам-мөхтәсибенең
яшьләр белән эшләү
буенча ярдәмчесе,
Сатыш авылы имам-хатыйб




Фото: elements.envato.com

# БАЛА ЧАКТА КҮРГӘН ТӨШНЕҢ ЧЫНГА АШУЫ

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

Йосыфның агалары карт әтиләрен, гаиләләрен һәм иң кечкенә энеләр Бинйәминне калдырып, Мисыр якларына килеп җитә. Һәм үзләренең бертуган энеләре булган Йосыф каршысына килеп баскач та, аны танымый. Ә Йосыф агаларының һәрберсен таный әмма үзенә никадәр генә авыр булса да, моны белдертми. Кай яклардан килүләре, гаиләләре турында сораштырганнан соң иң кечкенә энеләре Бинйәминне дә алып килергә куша. «Әгәр аны алып килмәсәгез, икенче юлы Мисырга ашлык өчен килеп тә тормагыз», – дип әйтә. Моннан тыш ул аларның ашлык өчен түләгән акчаларын да үзләренә кайтарып бирә. Агалары туган якларына кайткач әтиләренә сәфәрләре турында сөйли һәм Мисыр хакименең ярдәмчесе кечкенә энеләрен алып килүне сораганын әйтә. Әлбәттә, Ягъкуб галәйһиссәлам Бинйәминне җибәрергә каршы булса да, ахыр чиктә ризалашмыйча булдыра алмый.

Йосыф галәйһиссәламнең агалары кечкенә энеләре белән Мисырга килгәч, ул аларны каршы ала һәм башкаларга сиздермичә генә Бинйәмингә үзенең кем икәнен әйтә һәм моннан күп еллар элек үзе белән булган хәлләрне сөйли. Йосыф галәйһиссәлам энесен бик нык сагынган була, аны кочаклап алып, ничә еллар туганнарыннан, әтисеннән аерылып торуын искә ала. Моннан соң пәйгамбәр энесен Мисырда калдыруның бер юлын уйлап таба: агалары юлга чыгарга әзерләнә башлагач, ул Бинйәминнең капчыгына хакимнең кыйммәтле бер савытын салдыра. Икенче көнне агалары сәфәргә чыгып киткәч, сакчылар аларны туктата һәм капчыкларын тикшерә башлый. Кыйммәтле савыт Бинйәминнең капчыгында табылгач, агалары югалып кала. Энеләрен чит җирләрдә калдырмас, әтиләре янына алып кайту өчен нәрсә генә эшләсәләр дә, аларны беркем тыңламый: Бинйәмин Мисырда кала.

Бу көтелмәгән хәлдән бик нык борчуга төшеп, әтиләреннән бик нык оялып, аның саулыгы һәм гомере өчен кайгырып алар әтиләре янына туган якларына кайтып җитә. Йосыфны хәтерләткән баласы Бинйәминнең чит җирләрдә калуын белгәч, әтиләренең елый-елый кайгыдан күзләре сукырая. Әмма өметен өзмичә: «Миңа сабыр булырга кирәк. Бер көнне Аллаһы мине улларым белән күрештерер», – дип сабыр итә.

Күпмедер вакыттан соң Йосыфның агалары Мисырга килә һәм Йосыфтан энеләрен үзләре белән җибәрүен сорап үтенә башлый. Шуннан соң Йосыф алардан: «Сез энегез Йосыфны ни эшләттегез?» – дип сорый. Агалары куркып калып: «Син Йосыфмы әллә?» – дип сорый. Шундый зур кеше, үзенә кылынган начарлык өчен, хәзер аларны нәрсә эшләтер икән дип уйлап борчыла алар. Ләкин Йосыф, үзенә кылынган золымга карамастан, аларны гафу итә. Ул аларга: «Минем күлмәгемне әтиемә алып кайтыгыз. Күлмәктән килгән истән ул мине таныр», – дип әйтә һәм аларны кайтарып җибәрә. Уллары кайтып җиткәч, Ягъкуб пәйгамбәр күп еллар элек югалткан улының күлмәген танып, күкрәгенә кыса, күлмәкне йөзенә, күзләренә тидерә. Шул көнне аңа Аллаһының рәхмәте була: аның күзләре күрә башлый. Моннан соң пәйгамбәр уллары белән Мисыр җирләренә кузгала. Озак еллар аерылып торудан соң күрешкән ата белән улның ниләр кичергәнен сүз белән әйтеп бетереп булмастыр. Йосыф галәйһиссәлам әтисе Ягъкуб пәйгамбәргә: «Әти, менә Аллаһының ихтыяры белән, мин бала чакта күргән төш чынга ашты да инде», – дип әйтә.

Коръәни Кәримдә бу мизгел болай дип тасвирлана:

*«Ул атасы белән анасын [бик кыйммәтле] тәхеткә менгерде, һәм алар [уллары белән бергә сәлам бирер өчен] аңа сәҗдәгә [барып, җиргә] капландылар. [Шулвакыт Йосыф [галәйһиссәлам] Әйтте: «Ий әтием! Бу – минем элекке төшемнең аңлатмасы. Раббым аны бер хакыйкать итте. Ул мине зинданнан чыгарып; шәйтан минем белән кардәшләрем арасын бозганнан соң, сезне [барыгызны бергә бүген] чүлдән китереп, миңа [бик зур] игелек кылды. Һичшиксез, минем Раббым – [яшерен-ачык бөтен мәсьәләләрне бик яхшы белүче һәм барлыклар күзенә никадәр кыен күренсә дә] теләгәннәренә мәрхәмәт итүче. Һичшиксез, Ул – Белүче, Хикмәт иясе».*

*«Йосыф», 12:100*

Йосыф галәйһиссәлам гадел итеп Мисыр халкы белән идарә итә. Ул алар өчен юл күрсәтүче пәйгамбәр була. Үз үрнәгендә һәрвакытта да яхшылыкка һәм изгелеккә чакыра.


Сәхифәне
**Айсылу ЮЛДАШЕВА** әзерләде

# ИМАН ҺӘМ ЧИСТАРЫНУ

**Утка табынучы бер кеше имам Әгъзәм рахимәһуллаһига акча тиешле булган. Бервакыт Имам әҗәтен алыр өчен аның өенә килгән. Һәм аның өе янында имамның аяк киеме нәҗескә буялган. Ул аяк киемен салып, нәҗесне кагып төшергән, әмма пычрагы утка табынучы кешенең йортының диварына чәчрәгән.**

Имам Әгъзәм рахимәһуллаһи нәрсә эшләргә белмичә югалып калган. Үз-үзенә: «Әгәр мин бу нәҗесне диварда калдырып китсәм, дивар бик ямьсез булачак. Әгәр чистарта башласам – диварның штукатуры коелачак», – дигән. Һәм утка табынучы кешенең ишегенә шакыган. Ишекне хезмәтче ачкан. Имам аңа: «Хуҗага әйт, мин аны ишек алдында көтеп торам», – дигән.

Утка табынучы кеше өеннән чыккан да, имам әҗәтен сорарга килгәндер дип уйлап, гафу үтенә башлаган.


Фото: elements.envato.com

Имам Әгъзәм рахимәһуллаһи аңа: «Кем дә булса гафу үтенергә тиеш булса, ул мин», – дип әйткән дә, барысын да сөйләп биргән, диварны ничек чистартырга икән, дип сораган. Бу кеше: «Иң беренче чиратта минем күңелемне чистартырга кирәк», – дип җавап биргән һәм шунда ук иман китереп мөселман булган.

### НӘСЫЙХӘТ:

Ислам диненә гамәлләр белән чакыру сүз белән чакыруга караганда көчлерәк.

Болай дип риваять ителә: бер хатынның баласына бал ашарга ярамый торган булган, әмма әнисе күпме генә тырышса да, аны балдан тыя алмаган. Шуннан соң ул аның белән имам Әгъзәм рахимәһуллаһи янына килгән. Барысын да имамга сөйләп күрсәтеп, ярдәм итүен сораган. Имам Әгъзәм әни кешегә: «Миңа кырык көннән соң килерсең», – дигән. Кырык көн үткәннән соң имам Әгъзам балага: «Балам минем, бал ашама!» – дип әйткән.

Бу сүзләрдән соң әни кеше: «Син әлеге сүзләрне әйтер өчен безне кырык көн көттердеңме?» – дигән. Имам Әгъзәм: «Син миңа баланы алып килгәндә мин дә бал ашый идем. Әгәр мин бал ашаган көе, аңа ашамаска кушкан булсам, бу сүзләрнең тәэсире булмас иде», – дип җавап биргән.

# ИСМЕ ӘГЪЗАМ ДОГАСЫ

Бер кеше шәехкә килеп, аңа хезмәт итә башлый. Бервакыт ул аннан:

– Син мине Исме Әгъзам догасына өйрәтә алмыйсыңмы? – дип сорый. Шәех аңа:

– Алай булгач, шәһәр капкалары янына чык та, шунда тор, ә аннары күргәннәреңне миңа сөйләрсең, – дип әйтә.

Бу кеше шәһәр капкалары янына барып баса да көтеп тора башлый. Күпмедер вакыт үткәннән соң, ул утын кисүче карт кешене күрә. Ул үзе артыннан йөк төялгән ишәген алып бара. Бу вакытта аның янына сакчылар килеп, аны кыйнап, утыннарын тартып алалар.

Күзәтеп торучы бу кеше шәехе янына кайта да, күргәннәрен сөйләп бирә. Шәех аннан:

– Әгәр син Исме Әгъзам догасын белсәң, нәрсә эшләр идең? – дип сорый.

Ул:

– Мин сакчыларның һәлак булуларын теләп, дога кылыр идем, – дип җавап бирә. Шәех:

– Белеп тор: син күргән әлеге карт миңа Исме Әгъзам догасын өйрәтүче кеше. Бу доганы кешеләргә карата мәрхәмәтлелек һәм кызгану хисләренә ия булганнарга гына өйрәтәләр, – дип әйтә.

### НӘСЫЙХӘТ:

«Исме Әгъзам» – ул Аллаһы Тәгаләнең иң олуг исемнәрен үзенә туплаган доганың исеме. Бу кыйссадан шунысы аңлашыла: белгәнеңне һәр кешегә дә сөйләргә кирәкми. Бигрәк тә аңлый алмаган кешеләргә нечкә мәсьәләләрне төшендерергә тырышу дөрес түгел.

Гали радыяллаһу ганһе болай дип әйткән дип хәбәр ителә: «Сер – ул синең әсирең. Син аны ачып салсаң, үзең сереңнең әсире булырсың».

Югарыда искә алынганнан шуны да аңларга кирәк: шундук бәддога кыла башлау дөрес түгел.

Иң беренче чиратта, хаталанган кеше гаебен танысын өчен, дога кылу тиешле. Кешеләргә мәрхәмәтле һәм кайгыртучан мөнәсәбәттә булырга кирәк, чөнки без дә хаталанырга мөмкин. Моннан тыш, җәннәт бик киң һәм һәркемне үз эченә сыйдыра ала.

**«Рухуль Бәйан»** китабыннан



Фото: elements.envato.com

# КӘГАЗЬ БӘЯСЕНЕҢ ТАТАРЛАР ТОРМЫШЫН ҮЗГӘРТҮЕ

*Басма һәм кулъязма китапларының күпләп чыгарылуы татар халкының мәдәни үзгәрешенә башлангыч сала. Кәгазьгә бәяләр төшкәч, мәдрәсә шәкертләре үзләре өчен Коръәннең, хәдисләрнең һәм юридик (шәргый) китапларның күчермәләрен ясата. Алар шулай ук укытучылары тарафыннан язылган шигырьләр, фәтвалар һәм трактатларны да күчереп яза алган.*

**Мөгаен, кәгазь кебек бер генә товар да татар җәмәгатьчелегендә шулхәтле еракка бара торган үзгәрешләр китермәгәндер. XVII–XVIII гасырларда Идел-Урал регионында бөтенләй дә кәгазь җитештерелмәгән.**

Чыннан да XVIII гасыр буе диярлек Рәсәйдә кәгазь җитештерелми. Петр Великийның Рәсәйдә кәгазь промышленностен үстерү өчен куйган тырышлыкларына карамастан, Елизавета Петровна (1741–1762) идарә иткән вакытта Рәсәй түрәләр һәм аларның хезмәткәрләре кулланган кәгазьнең яртысыннан азрагын гына җитештергән дип саналган.

Шуңа да империя бюрократиясе һәм Рәсәй халкы ул вакытта кәгазь промышленносте күпмедер дәрәҗәдә алга киткән Көнбатыш һәм Үзәк Аурупа (Нидерланд, Франция һәм башка) илләреннән килгән кәгазьгә таяна.

Ырынбургтан Урта Азия һәм Һинд ханлыкларына илтә торган сәүдә юлларында яшәүче мөселманнарның һинд һәм фарсы кәгазен алу мөмкинлеге булган.

Әмма XVIII гасырда һинд һәм фарсы җитештерүчеләре үз эшләрен, Аурупа хезмәттәшләре кебек үк, механикалаштырмаган була.

Су энергиясен кулланып, аурупалылар кәгазьне югары сыйфатлы итеп, күпләп чыгара алган.

Рәсәй административ-идарә үзәкләрендә һәм алар янында еш эшләүче татар галимнәре өчен Аурупа кәгазе, һинд һәм фарсы кәгазенә караганда, арзан һәм күп күләмдә булган.

XVIII гасырның уртасыннан алып, рус хакимнәре кәгазьне үз ватаннарында җитештерү буенча җитди карарлар кабул итә, шул исәптән, рәсми эш башкару рус кәгазендә алып барылырга тиеш, дигән фәрман бирә.

Моннан соң Рәсәйдә кәгазь җитештерүчеләрнең саны кинәт артып китә. Шул ук вакытта Аурупа кәгазен җитештерүчеләр, үсеп килә торган ихтыяҗны канәгатьләндерү өчен, киңәюне дәвам итә.

Рәсәй кулланучылары өчен бу үзгәрешләрнең гомуми нәтиҗәсе XVIII гасырның азагына күренә: кәгазь өчен тәкъдим арта, ә бәя кими.

Үз илебездә җитештерелгән кәгазь Рәсәйдә киң таралыш ала, ә Аурупа кәгазен нигездә Бөекбритания, Франция һәм Үзәк Аурупа илләреннән ала башлыйлар.

Чәй кебек үк, кәгазь зиннәт предметыннан гади мөселманнарның көнкүреш тормышына үтеп кергән товарга әйләнә.

XVIII гасырда Казан губерниясендә яшәүче крестьян яки авыл мулласы гаиләсе күп булмаган санда кулъязма китапларына ия була.

XIX гасыр уртасына авыл имамнары үзләренең зур булмаган китапханәләрен җыю мөмкинлегенә ирешә, ә крестьяннар догалыклар, сайланма сүрәләрне генә үз эченә алган Коръән китабын, шигъри әсәрләрне һәм халык җырлары җыентыкларын үзләрендә булдырган.

Текстларны күчереп алу истә калдыруда да зур роль уйнаган. Дөрес, барысы да үз китапларының күчермәсен эшләмәгән. Хәллерәк галимнәр генә күчермә төшерү өчен башкаларга түли алган.

XIX гасыр башына кулъязмаларны бүләк итү, сатып алу, сату, шулай ук заказга булдыру мөмкинлеге дә булган. 1780 елларда китап бастыру эшен кертеп җибәрү яңа мәдәниятне формалаштыра. XX гасыр башына гарәп язулы китаплар меңләп һәм ун меңләп данәдә бастырыла башлый.

Бу продукт татар һәм башка төрки телле мөселманнарның җәмәгатьчелегенә сизелерлек тәэсир ясый. Шул рәвешле, XIX-XX гасыр башында арзанлы кәгазь татар халкының иҗтимагый һәм мәдәни үсешенә мөһим этәргеч була.

**Дамир Гайнетдинов язмасы,**
islam-today.ru сайтыннан
тәрҗемә

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 09 (326) сентябрь, 2022 | сафәр, 1444




# КОРЪӘНДӘ ҮЛӘННӘРНЕҢ ШИФАЛЫ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ ТУРЫНДА НИЛӘР ӘЙТЕЛГӘН?

**Янәшәбездә генә үсеп яткан үләннәрнең күптөрлелеге һәм бу күптөрлелекнең сәбәбе турында кайчан да булса уйлап караганыбыз бармы? Төссез кара туфрактан төрле төстәге, бер-берсенә охшамаган, әле шундый хуш исле чәчәкләрнең ничек үсеп чыкканлыгы турында?! Менә – аклы-сарылы ромашкалар, ә менә – сирень куагы, зәңгәр һиндыба (цикорий) чәчәге, ә янәшәсендә генә – сары һәм мамыктай йомшак тузганаклар! Еллар һәм гасырлар үтү белән әлеге үсемлекләр үз төсләрен, рәвешләрен һәм чәчәк ату вакытларын үзгәртми. Бу исә – бу үсемлекләрдә үзләренә генә хас генетик кодлар барлыгына бер ишарәт. Шул ук нәрсәне хайваннар, кошлар, балыклар һәм бөҗәкләр дөньясында да күзәтергә мөмкин. Бака уылдыгыннан – балык, ташбака йомыркасыннан – крокодил чыкмаган кебек; мәчедән эт тууы, чия төшеннән дә кузаклы фасоль үсеп чыгуы һич мөмкин түгел.**

Күзләребезне бу хакыйкатьләргә ачып, Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә безгә болай дип хитап кыла:

*«Бер-берсенең янәшәсендә яткан кишәрләрдә йөзем бакчалары, игеннәр, тамырлары уртак һәм аерым булган хөрмәлекләр [үсә], [болар бөтенесе] бер үк су белән сугарыла. Алай да Без [җимешләрнең] берләрен [шәкел, тәм, исләре белән] икенчеләреннән өстен кылабыз. Һичшиксез, акыл ияләре өчен монда [бар итүченең өстен көченә күрсәткән ачык] билгеләр бар».*

*«Әр-Рагъд / Күк күкрәү», 13:4*

Башка бер аятьтә болай диелә:

*«[Бодай һәм арпа кебек] Яфраклы игеннәр һәм хуш исле үләннәр бар».*

*«Әр-Рахмән / Мәрхәмәтле», 55:12*

Янәшәбездәге хайван һәм үсемлекләрнең тышкы кыяфәтләрендәге пропорция һәм симметрияләргә күз салсак, Аллаһының бу эшләрдә катнашы тагы да ачыграк күренә. Бу хакта Әл-Әгълә сүрәсенең беренче аятьләрендә болай диелгән:

*«Бөек булган Раббыңның исемен тәсбих ит. Ул [һәрнәрсәне] яратты һәм төзек итте. Ул [барлыкларның җенесләрен, төрләрен үлчәп] тәкъдир итте һәм [яратылыш максатына] юнәлдерде. Ул [терлекләргә] утлауларны чыгарды. Шуннан [аның яшел хәленнән] соң аны кап-кара чүпкә әйләндерә».*

*«Әгълә / Иң өстен», 87:1–5*

## «АВЫРУНЫ ТАНЫГАН – ДӘВАСЫН ТАБАР»

Чир һәм вәбаларга каршы көчсезлеге һәм үлемнән курку кешене элек-электән әйләнә-тирә табигатькә ярдәм артыннан мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр иткән. Сиземләве белән кеше бу җирдә ялгыз түгеллеген, исән калу өчен әйләнә-тирә мохиттан котылу чарасын эзләп табып кына котылачагын ул аңлап яшәгән. Адәм баласының дөньяга мондый карашын Коръәни Кәрим дә раслый:

*«Без әйттек: «Барыгыз бергә моннан төшегез! Әгәр Миннән сезгә һидаять килсә, кемнәр Минем һидаятемә иярә, шуларга бернинди курку да булмас, алар хәсрәт тә чикмәс»;*

*«Әл-Бәкара / Сыер», 2:38*

*«[Шулвакыт Аллаһы Адәм, Хава һәм Иблискә мөрәҗәгать итеп] Әйтте: «Бер-берләрегезгә дошман буларак [җәннәттән] чыгыгыз. Сезгә яшәү урыны һәм [әҗәлегез җитеп үлгәнчегә кадәр] вакытлыча файдалану урыны – җирдә».*

*«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:24*

*Ягъни, җиргә килгәннән соң, кеше имин тормыш көтәр өчен Раббысыннан күрсәтмә көтеп утырырга гына тиеш түгел, бәлки үзе дә шундый күрсәткечләрне эзләп табарга тиеш булган. Моның хакта пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә: «Аллаһы Тәгалә нинди генә авыруны җибәрсә дә, һичшиксез, аның белән бергә дәвасын да җибәрә. Аны (авыруны) таныган – дәвасын белер, танымаган – белмәс», – дигән («Мөснәд», Әхмәд бине Хәнбәл).*

Һәм кеше әлеге дәваны эзләгән. Аллаһыга ышанучылар гына түгел, атеистлар да эзләгән. Мәсәлән, СССР-да 1931 елда, хәзерге көндә дә эшләп килә торган, дару һәм хуш исле үсемлекләрне өйрәнүче Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү институты ачыла. Бу институт инде менә йөз елга якын СССРда, Рәсәй Федерациясендә һәм чит илләрдә үсә торган кыргый дару үсемлекләрен өйрәнү белән шөгыльләнә; өйрәнелгән үсемлекләрдән бүленеп чыгарылган биологик актив матдәләр нигезендә, дәвалау препаратларын җитештерү технологияләрен эшләп чыгара. Институтның эшләү дәверендә аның лабораторияләрендә үсемлекләрдән 120 дән артык дәвалау препараты уйлап табылган.

## ДАРУ ҮЛӘННӘРЕНДӘГЕ ШИФА КАЙДАН КИЛГӘН?

Әмма мәкаләбезнең темасына әйләнеп кайтып, дару үләннәрендәге дәвалау үзлеге нидән гыйбарәт икәнлеге турында да бераз фикер йөртеп карыйк. Үсемлекләр дәвалау матдәләре чыганакларының берсе булуы турында Коръәни Кәримдә болай диелә:

*«[Расүлем!] Синең Раббың бал кортына вәхи итте: «Тауларда, агачларда һәм [кешеләр төзегән] корылмаларда оялар кор. Шуннан соң, һәртөрле җимешләрдән туклан һәм Раббың җиңеләйткән юлларда йөр». Аларның карыннарыннан [ел фасылларының, чәчәкләрнең, бал кортларының яше үзгәрүгә бәйле] төрле төсле һәм кешеләр өчен шифа булган бер эчемлек чыга. Һичшиксез, боларда фикер йөртүчеләр өчен билге бар».*

*«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:68-69*

Димәк, балдагы дәвалау сыйфатларына ия булган матдәләр иң элек бал корты туклана торган чәчәкләрнең серкәләрендә тупланган. Бу исә – кешеләр һәм хайваннар өчен шифалы матдәләрнең беренчел чыганагы – үсемлекләр булып торганлыгына ишарәт булып тора.

## ВИТАМИННАРНЫҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ

Әле 1880 елда рус табибы һәм галиме Н.И. Лунин ашый торган ризыгыбызда, углеводлардан, майлардан, аксымнардан һәм минераль матдәләрдән тыш, ул вакытта әле фәнгә билгеле булмаган, организмның эшчәнлегенә этәргеч бирә торган махсус матдәләр булырга тиешлеген күрсәткән. 1895 елда рус патофизиологы В. В. Пашутин да сәяхәтчеләр һәм диңгезчеләр арасында киң таралган, миллионлаган гомерләрне алып киткән цинга кебек авыру түбән сыйфатлы туклану белән бәйле рәвештә алга китүен фаразлый. Бу, организмның үзендә түгел, ә үсемлек продуктларында синтезлана торган кайбер органик матдәләрнең ризыкта җитмәве белән бәйле булганлыгы турында фикер әйтелә. 1932 елда бу фараз Америка галимнәре тарафыннан раслана, цинга авыруының организмда бары С витамины җитмәүдән барлыкка килүе хакында әйтелә. Бу ачышны ясаучы галимнәр физиология һәм медицина өлкәсендә Нобель премиясенә лаек була. 1929 елда Нидерланд табибы Христиан Эйкман «бери-бери» авыруының туклану рационының кимчелекле булуы сәбәпле барлыкка килүе турында әйтә, бу В төркеме витаминнарның ачылышына сәбәп була. Моның өчен дә галим Нобель премиясенә лаек була.

Кеше организмының нормаль эшчәнлеге өчен гаять мөһим роль уйнаган бу биологик актив матдәләрне лаборатория ысулы белән үләннәрдән чыгарырга өйрәнеп, кеше аларны «витаминнар», ягъни терелтеп җибәрүче, яшәешкә этәргеч бирүче матдәләр дип атый. Һәм кешенең тәүлеккә витаминнарга ихтыяҗы зур булмаса да, ул миллиграммнарда гына санала, аларның кеше сәламәтлеге һәм тормышы өчен роле гадәттән тыш зур.

## АЯК АСТЫНДАГЫ ХӘЗИНӘ

Бу тылсымлы матдәләр турында 1400 ел элек иңгән Коръәни Кәримдә дә әйтелми калмаган:

*«Без җирне дә [файдалансыннар дип] җәеп салдык, өстенә какшамас таулар куйдык, һәм үлчәүле [җимешләрдән] һәртөрле нәрсәне анда үстердек. Сезнең өчен дә, сез ризыкландырмаганнар өчен дә [азык-төлек һәм кием-салым кебек] яшәү кирәк-яраклaрын анда яралттык. Хәзинәләре Бездә булмаган бер генә нәрсә дә юк. Әмма [туфракка яңгыр һәммә җиргә дә бертигез яумаганы кебек, һәр җан иясенә кирәкле нигъмәт вә рәхмәт тә төрлечә булганлыктан] Без аны] билгеле бер микъдарда гына иңдерәбез».*

*«Әл-Хиҗр», 15:19-21*

Әлеге аятьтән аңлашылганча, җирдә үсә торган үсемлекләр, санап бетергесез күп булса да, һәрберсе кирәкле күләмдә һәм билгеле бер микъдарда гына үсә. Аятьтә кулланылган «мәүзүн» сыйфат фигыле «вәзн» тамырыннан ясалып, гарәп телендә «микъдар», «авырлык», «пропорция» дигән мәгънәдә килә. Аятьтә шулай ук мәхлүкъларның тереклеген куәтләп һәм баетып тору өчен, кирәкле күләмдә генә «индерелә» торган кыйммәтләр турында да әйтелә, бу байлыклар тупланып саклана торган «келәтләр» – гарәпчә «хәзинә» сүзенең күплек саны – «хазәин» сүзе белән тасвирлана.

Шулай булгач, сорау туа: кеше һәм, гомумән, тереклек өчен гаять файдалы, әмма билгеле бер микъдарда гына үсемлекләрдә хасил булган шушы биологик актив матдәләрнең барлыгы турында хәзерге заман фәнендә дә билгеле булып та, Коръәни Кәримдә искә алынмавы мөмкинме? Һәм аятьттәге «хәзинәләр» – табигатьтә яшеренгән һәм тереклек өчен билгеле әһәмияткә һәм кыйммәткә ия булган витаминнар икәнен әйтеп буламы? Моны укучы үзе уйлап әйтсен.

**Альберт Кадыйров,**
Казан шәһәре Дәрвишләр бистәсе мәчете мәхәллә әгъзасы, тәрҗемәче

# Сөннәтче бабай


Фото: shutterstock.com

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

Бу тавыклар, әтәчләр, кәҗәләр – һәммәсе дә Сөннәтче бабай кеби карт булсалар да, Сөннәтче бабай күрше картларыннан аерылган кеби, анлар да күрше тавыкларыннан, әтәчләреннән аерылсалар да, һәммәсе дә холыклары, табигатьләре берлән Сөннәтче бабайга бик охшасалар да, күрше-фәлән, ни өчендер, бу мәсьәләдә Сөннәтче бабайның хакыны кабул итмәенчә, Гөлйөзем әбигә нисбат биргәннәр иде. Кем белсен, өй, бакча, миләш Сөннәтче бабайга никадәр охшаса, тавык, әтәч, кәҗә, бәлки, Гөлйөзем әбигә шулкадәр охшагандыр. Шулай дигәч тә, сез Гөлйөзем әби берлән Сөннәтче бабай арасында аерма бар иде, берсе кара туткыллы, берсе сарырак; берсе каты табигатьле, берсе йомшак, берсе матур, берсе ямьсез иде, дип, бер хата фикер чыгармаңыз. Бонларның төсләрендә, йөзләрендә, кылынышларында, табигатьләрендә дә һичбер аерма юк иде. Дөресте генә, бонлар хәзер ике кеше түгел, икедән кушып ясалган бер кеше иде. Бонларның берсен күреп, икенчесен күрмәгән кеше иттифакый (очраклы. ред.) күрмәгәнен, икенче авылда яисә кара урманның ялтыраган аланында җиләк җыйганда күрсә, мотлака (һичшиксез. ред.), моның кем икәнлеген таныячак иде.

Бонларның төсләре генә түгел, уйлары да берләшеп беткән иде. Мәсәлән, Сөннәтче бабай: «Карчык, түтәлләргә сибәргә вакыт түгелме?» – диярргә өлгерә алмый иде, Гөлйөзем әби чиләкне күтәреп чыга башлый иде. Көз җитеп, «сөннәт туйлары» җитә башларга вакыт җитеп, Гөлйөзем әби: «Карт, «сөннәтләр» җитә», – диярргә өлгерми, Сөннәтче бабай, тәһарәт төзеп, чалгы пәкесен кайрарга тотына иде. Алай булса да, болар үзләре бер-берсене аералар иде. Гөлйөзем әби бер вакытта да Сөннәтче бабайга «карчык» дип дәшми, бабай да, онытып җибәреп, карчыгына «картым» дип эндәшми иде.

Ул гына да түгел, бонлар арасында эштә дә аерма бар иде: кәҗә саву, тавыклар ашату, йомырка җыю, самовар кую Гөлйөзем әбинең эше булган кеби, миләшкә су сибү, йортны себерү, канауларны төзәтү дә Сөннәтче бабайның гына эше иде. Онытканмын икән әле, өй җыештыру да бөтенләй Гөлйөзем әбинең җилкәсендә иде. Ул һәр көнне әллә ничә мәртәбә идәнне себерә, һәр атна кич ком берлән сап-сары итеп самоварны ача, айда бер өйнең ярыкларын ямар өчен сылаган балчык өстеннән акбур белән буйый, һәр намаз алдыннан картының комганына су сала иде.

Өйләрендә әллә никадәр җиһазлар булмаса да, җәмәгатьләре шул карт, карчык берлән бетсә дә, Гөлйөзем әби көн буе эштән бушамый иде. Ул кай вакытлар мич ягып күмәч сала, кыстыбый пешерә, бәйрәм көннәрендә картының намаздан кайтуына коймак хәзерләп куя иде. Өйдәге бөтен әйберләр, җиһазларда һич артык нәрсә булмаса да, бонлар арасында берсе дә кыйммәтле, кыйммәтсезлек берлән аерылмаса да, өч нәрсә бонларга һич охшамаган, бөтенләй башка дәрәҗәдә иде: аның берсе — Сөннәтче бабайның мирас юлы берлән сөннәтчелеккә хакы барлыгының исбат итә торган шәҗәрәсе, икенчесе — сөннәт кисә торган чалгы пәкесе, өченчесе сөннәткә сибә торган, шешәгә тутырган сары черепеге иде. Бонларның өчесе дә өйнең иң кадерле җирендә, Гөлйөзем әбинең кыз чагыннан калган «һәфтияге», бөтиләре саклана торган түрдәге шүрлектә, кечкенә сандыкта тора иде. Бонларның һичберсе дә гади көндә алынмый, һичберсе андый-мондый эшкә тотылмый иде. Хосусән шәҗәрәнең кыйммәте әби берлән бабай алдында бик зур иде. Ул һәрвакыт карындыкка төрелгән көенчә, берничә кат кәгазьгә сарылып, чүпрәкләр берлән бәйләнеп куелган иде. Аның эчендә ни язылганын Сөннәтче бабай укый белмәсә дә, шул кәгазьнең бик зур кәгазь икәнен белә, әллә нидә бер зур кунак-фәләнгә күрсәтергә тугъры килсә, ул, шәҗәрәнең бер җирендәге исемгә бармагы берлән төртеп:

– Менә монысы — Сәлман Фарси разый аллаһе ганһе, менә монысы — мин, – дия иде.

Ул шул сүзне әйткәндә бераз һаваланып та киткән кеби була; теге кешегә гади кеше берлән эш итмәгәнен, «Сәлман Фарси» нәселеннән бер кеше берлән эш иткәнене белдерер өчен кеби:

– Сәлман Фарси хәзрәтләре безнең бабамыз булган, – дип куя иде.

Аннан соң ул шәҗәрәнең тарихын сөйләргә тотына иде. Сөйләгәндә, гади сүз сәйләмәгәнен белгәнгә, сүз араларында салаватлар әйтә, «Разый аллаһе ганһе, рәхматуллаһи галәйһи»ләр берлә бизәкли иде.

Бабай ул шәҗәрәне әтисеннән мирас тарикынча алган иде. Шуннан соң аңар үзенең исемене яздырыр өчен мәрхүм — алла рәхмәтендә булсын! — Түнтәр (Гали ишан) хәзрәткә барган иде.

*(Дәвамы киләсе санда)*

**Гаяз Исхакый**

## Кәсеп турында

*Яшәү өчен хәләлне син кәсеп ит,*
*Ризыкны тап көчең җиткән*
*кадәр тик.*
*Ходаның биргәнен азсынма,*
*зинһар,*
*Аның хөкмендә бит барлык*
*ризыклар.*
*Тудырды ул анадан яп-ялангач,*
*Киендерде, карын да итмәде ач.*
*Ана карнында безне тотты*
*ул тук,*
*Тагын да туйдырыр,*
*мохтаҗлыгы юк.*

**Габдрәхим Утыз Имәни**

**ДҮШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ҖОМГА, ЯКШӘМБЕ**

**07:00** Вәгазь вакыты
**07:30** «Шөкер хуҗа» мультфильмы
**07:40** «Тәмле булсын»
**08:00** «Бер сорау – бер хәдис»
**08:10** «Җилкәй» мультфильмы
**08:25** Онлайн мәдрәсә
**08:45** «Бер мәчет тарихы»
**08:55** «Пәйгәмбәр сүзе эзеннән»
**09:30** Әлифба. Коръән уку сабаклары
**09:50** «Рухел-Бәйан»
**09:55** «Коръән могҗизалары»
**10:05** «Дин турында»
**10:35** Намазга өйрәник (хатын кызлар өчен)
**10:55** «Имамнан сорыйк»
**11:40** «Мәслихәт»
**12:00** Азан
**12:05** «Узнаем у имама»
**12:50** Знамения Корана
**13:00** Конкурс чтецов Корана
**13:25** «Кул Шариф. Возрождение»
**14:50** «В тени милости Аллаха»
**15:00** Художественный сериал
**16:00** Вәгазь вакыты
**16:30** «Шөкер хуҗа» мультфильм
**16:40** «Тәмле булсын»
**17:00** «Бер сорау – бер хәдис»
**17:10** «Җилкәй» мультфильм
**17:25** Онлайн мәдрәсә
**17:45** «Бер мәчет тарихы»
**17:55** «Пәйгәмбәр сүзе эзеннән»
**18:30** Әлифба. Коръән уку сабаклары
**18:50** «Рухел-Бәйан»
**18:55** «Коръән могҗизалары»
**19:05** «Дин турында»
**19:35** Намазга өйрәник (ир-атлар өчен)
**19:55** «Имамнан сорыйк»
**20:40** «Мәслихәт»
**21:00** «Узнаем у имама»
**21:45** Знамения Корана
**21:55** Конкурс чтецов Корана
**22:20** «Кул Шариф. Возрождение»
**23:45** «В тени милости Аллаха»
**23:55** Художественный сериал
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод

**СИШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ, ШИМБӘ**

**07:00** Вәгазь вакыты
**07:30** «Билал» мультфильм
**08:00** «Хәдис дәресләре»
**08:20** «Бер сорау – бер хәдис»
**08:30** «Күңелдән күңелгә»
**08:45** Әлифба. Коръән уку сабаклары
**09:05** «Бер мәчет тарихы»
**09:15** «Пәйгәмбәр сүзе эзеннән»
**09:50** Онлайн мәдрәсә
**10:10** «Рухел-Бәйан»
**10:15** «Коръән могҗизалары»
**10:25** Дин турында
**10:55** Намазга өйрәник (хатын кызлар өчен)
**11:15** «Имамнан сорыйк»
**12:00** Азан
**12:05** «Азбука ислама»
**12:25** Знамения Корана
**12:35** «Без татарлар»
**13:15** «Есть вопрос – есть хадис»
**13:25** Художественный сериал
**14:25** «Аль-Истикама»
**14:45** «Халяль-лайфстайл»
**15:00** «Ислам сегодня»
**15:35** «Мастерская вкуса»
**15:50** «Энцеклопедия для маленьких мусульман»
**16:00** Вәгазь вакыты
**16:30** «Билал» мультфильм
**17:00** «Хәдис дәресләре»
**17:20** «Бер сорау – бер хәдис»
**17:30** «Күңелдән күңелгә»
**17:45** Әлифба. Коръән уку сабаклары
**18:05** «Бер мәчет тарихы»
**18:15** «Пәйгәмбәр сүзе эзеннән»
**18:50** Онлайн мәдрәсә
**19:10** «Рухел-Бәйан»
**19:15** «Коръән могҗизалары»
**19:25** Дин турында
**19:55** Намазга өйрәник (ир-атлар өчен)
**20:15** «Имамнан сорыйк»
**21:00** «Азбука ислама»
**21:20** «Знамения Корана»
**21:30** «Без татарлар»
**22:10** «Есть вопрос-есть хадис»
**22:20** Художественный сериал
**23:20** «Аль-Истикама»
**23:40** «Халяль-лайфстайл»
**23:55** «Ислам сегодня»
**00:30** «Мастерская вкуса»
**00:45** «Энциклопедия для маленьких мусульман»
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод




## «ХОЗУР» НӘШРИЯТ ЙОРТЫ ШАГЫЙРӘ РӘЗИНӘ МӨХИЯРНЕҢ **«ИМАН КӨЧЕ»** ДИП АТАЛГАН ШИГЪРИ ҖЫЕНТЫГЫН НӘШЕР ИТТТЕ

Җыентыкта төрле яшьтәге балалар өчен дини һәм әхлакый эчтәлекле шигырьләр тупланган. Ул балалар бакчалары тәрбиячеләренә, укытучыларга һәм мәктәп укучыларына тәкъдим ителә. Аллаһы Тәгаләнең мәхлукълары турында энҗе-бөртек шигъри тәлгәшләрдән танып белү тагын да кызыклырак булыр һәм һәр кешенең күңеленә үтеп керә алыр.

**Китапны «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм дистанцион рәвештә заказ бирергә мөмкин.**
**Кибет:** Казан шәһ., Париж Коммунасы ур., 6нчы йорт. Тел.: +7 (960) 072-74-63;
**Склад:** Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт. Тел.: +7 (966) 250-00-09;
**Интернет-кибет:** huzurshop.ru

Реклама. +12

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**

Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН;**

«Хозур» нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**

ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе **Булат МӨБАРӘКОВ;**

Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**

ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррир: **Юлдашева А. И.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Шәйхетдинов А. Х.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**НӘШИР:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт).
Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.

Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.

Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә. Заказ №2733.
График буенча – 26 нчы сентябрь 21.00, гамәлдә – 21.00 сәгатьтә кул куелды.

Газетага ярты елга язылу бәясе – 140, 40 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 28 нче сентябрь көнне таратыла.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

## ОКТЯБРЬ 2022 / КАЗАН

| Көн | Көн исеме | ИРТӘНГЕ НАМАЗ: Сәхәр тәмам | ИРТӘНГЕ НАМАЗ: Мәчетләрдә укыла | Кояш чыга | Зәвәл | ӨЙЛӘ НАМАЗЫ | ИКЕНДЕ НАМАЗЫ | АХШАМ НАМАЗЫ / ИФТАР | ЯСТУ НАМАЗЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 01 | Шим | 03:41 | 04:15 | 05:45 | 11:33 | 12:00 | 15:19 | 17:19 | 19:01 |
| 02 | Якш | 03:43 | 04:17 | 05:47 | 11:32 | 12:00 | 15:16 | 17:17 | 18:58 |
| 03 | Дүш | 03:45 | 04:19 | 05:49 | 11:32 | 12:00 | 15:14 | 17:14 | 18:55 |
| 04 | Сиш | 03:47 | 04:21 | 05:51 | 11:32 | 12:00 | 15:12 | 17:11 | 18:53 |
| 05 | Чәрш | 03:49 | 04:23 | 05:53 | 11:31 | 12:00 | 15:10 | 17:09 | 18:50 |
| 06 | Пәнҗ | 03:51 | 04:25 | 05:55 | 11:31 | 12:00 | 15:07 | 17:06 | 18:47 |
| 07 | Җом | 03:54 | 04:27 | 05:57 | 11:31 | 12:00 | 15:05 | 17:04 | 18:45 |
| 08 | Шим | 03:56 | 04:29 | 05:59 | 11:31 | 12:00 | 15:03 | 17:01 | 18:42 |
| 09 | Якш | 03:58 | 04:31 | 06:01 | 11:30 | 12:00 | 15:00 | 16:58 | 18:39 |
| 10 | Дүш | 04:00 | 04:33 | 06:03 | 11:30 | 12:00 | 14:58 | 16:56 | 18:37 |
| 11 | Сиш | 04:02 | 04:35 | 06:05 | 11:30 | 12:00 | 14:56 | 16:53 | 18:34 |
| 12 | Чәрш | 04:04 | 04:37 | 06:07 | 11:30 | 12:00 | 14:54 | 16:51 | 18:32 |
| 13 | Пәнҗ | 04:06 | 04:39 | 06:09 | 11:29 | 12:00 | 14:51 | 16:48 | 18:29 |
| 14 | Җом | 04:08 | 04:41 | 06:11 | 11:29 | 12:00 | 14:49 | 16:46 | 18:27 |
| 15 | Шим | 04:10 | 04:43 | 06:13 | 11:29 | 12:00 | 14:47 | 16:43 | 18:25 |
| 16 | Якш | 04:12 | 04:45 | 06:15 | 11:29 | 12:00 | 14:45 | 16:41 | 18:22 |
| 17 | Дүш | 04:14 | 04:47 | 06:17 | 11:28 | 12:00 | 14:42 | 16:38 | 18:20 |
| 18 | Сиш | 04:16 | 04:49 | 06:19 | 11:28 | 12:00 | 14:40 | 16:36 | 18:18 |
| 19 | Чәрш | 04:18 | 04:51 | 06:21 | 11:28 | 12:00 | 14:38 | 16:34 | 18:15 |
| 20 | Пәнҗ | 04:20 | 04:53 | 06:23 | 11:28 | 12:00 | 14:36 | 16:31 | 18:13 |
| 21 | Җом | 04:22 | 04:56 | 06:26 | 11:28 | 12:00 | 14:34 | 16:29 | 18:11 |
| 22 | Шим | 04:24 | 04:58 | 06:28 | 11:27 | 12:00 | 14:32 | 16:26 | 18:09 |
| 23 | Якш | 04:26 | 05:00 | 06:30 | 11:27 | 12:00 | 14:29 | 16:24 | 18:06 |
| 24 | Дүш | 04:28 | 05:02 | 06:32 | 11:27 | 12:00 | 14:27 | 16:22 | 18:04 |
| 25 | Сиш | 04:30 | 05:04 | 06:34 | 11:27 | 12:00 | 14:25 | 16:19 | 18:02 |
| 26 | Чәрш | 04:32 | 05:06 | 06:36 | 11:27 | 12:00 | 14:23 | 16:17 | 18:00 |
| 27 | Пәнҗ | 04:33 | 05:08 | 06:38 | 11:27 | 12:00 | 14:21 | 16:15 | 17:58 |
| 28 | Җом | 04:35 | 05:10 | 06:40 | 11:27 | 12:00 | 14:19 | 16:13 | 17:56 |
| 29 | Шим | 04:37 | 05:12 | 06:42 | 11:27 | 12:00 | 14:17 | 16:10 | 17:54 |
| 30 | Якш | 04:39 | 05:14 | 06:44 | 11:27 | 12:00 | 14:15 | 16:08 | 17:52 |
| 31 | Дүш | 04:41 | 05:16 | 06:46 | 11:27 | 12:00 | 14:13 | 16:06 | 17:50 |